**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Түбән Кама шәһәренең шәһәр зираты территориясендә җәнлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында**

Җәнлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Җәнлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле Түбән Кама шәһәренең шәһәр зираты территориясендә карантин кертергә.

2. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, җәнлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә җәнлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел,11 гыйнвар
№ ПУ-3